күп профильле
181 нче мәктәп

# Күкнең җиденче катында

6 нчы чыгарылыш

28 нче февраль

БУ САНДА:


| | |
|---|---|
| Туган тел көне | 1 |
| Мәктәп яңалыклары | 2 |
| Муса Җәлилнең әдәби мирасы | 3 |
| Тәрбияле бала сәхифәсе | 4 |








Халыкара туган тел көне - 21 февраль көнне билгеләнгән, ЮНЕСКО Генераль конференциясе тарафыннан игълан ителгән халыкара бәйрәм. Бөтен дөньядагы туган телләрне, аеруча аз санлы халыкларның телләрен, тануга, үстерүгә булышлык итү максатында, 1999 елның 17 ноябрендә ЮНЕСКОның генераль конференциясендә Халыкара туган тел көнен билгеләү турында карар кабул ителә. 2000 елның февраленнән башлап ел саен тел һәм мәдәниятның төрлелегенә һәм күптеллелегенә ярдәм итү максатыннан дөньякүләм билгеләп үтелә.

Татар теле тугач та иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күп гасырлык тарихы булган, Каюм Насыйрилар, Тукайлар нигез салган, 7 миллион халык сөйләшкән, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, бүгенге көндә җитлеккән, камилләшкән, теләсә нинди катлаулы фәнне өйрәтергә мөмкинлеге булган, иң-иң авыр кимсетүләргә дә түзгән, сынмаган-сыгылмаган, баш имәгән горур татар теле!

# Строй һәм җыр смотр-конкурсы

18 нче февраль көнне мәктәбебездә «Строй һәм җыр смотры» бәйгесе булып узды. Бәйгедә 2-8, 10 нчы сыйныф укучылары катнашты. Жюри строй әзерлеген, командаларның дөрес үтәлешен, тантаналы марш белән узуын, тигезлеген бәяләде. Бәйгедә 28 класс укучысы катнашты. Һәр команда югары әзерлек һәм бердәм эш күрсәтте.





### Йөзү буенча ...

Йөзү буенча җыелма команда шәһәр этабында

призлы урын яулады: егетләр - 2 нче урын, кызлар-3 нче урын. Җиңүчеләрне котлыйбыз!

### Танкист-геройлар бюсты ачылышы

Мәктәбебезнең «Патриот» исемендәге Юнармия отряды, 22 нче февраль көнне, Казан югары хәрби танк училищесында узган Танкист-геройлар бюсты ачылышында булдылар.

Училище территориясендә барлыгы 11 яңа бюст барлыкка килде:

генерал-майор М.М.Шәйморатов

генерал-майор Р.А.Шадрин

өлкән лейтенант И.Н.Ахпашев

өлкән лейтенант В.Н.Горин

майор С.В.Кустов

кече лейтенант К.В.Ситкин

майор Т.О.Мусалаев

өлкән лейтенант М.И.Михайлов

өлкән лейтенант И.Л.Насыйбуллин

өлкән лейтенант Д.Э.Шәймәрданов

майор С.А.Панов

Әлеге хәрбиләр үлгәннән соң бүләкләнде.

Чара ахырында батырларның туганнары «Герой-танкистлар» һәйкәленә чәчәк салды.





Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып.
Мәңге үлмәс...

# Муса Җәлилнең әдәби мирасы

М. Җәлилнең әдәби мирасы күп милләтле совет әдәбиятының кыйммәтле бер казанышы булып тора. Аның әсәрләре кешеләрдә матур, гуманистик тойгылар уята, аларны тормыштагы матурлыкны күрергә һәм шул матурлык өчен көрәшергә чакыра.

«Моабит дәфтәрләре» - Җәлил поэзиясенең иң югары ноктасы. Моабит шигырьләрендә шагыйрьнең шәхси образы, кичерешләре, фәлсәфи уйланулары аша кеше рухының бөеклеге, куркусызлыгы, гуманистик табигате, гаделлек һәм хаклык тантанасына якты ышанычы, туган иленә, туган халкына чиксез мәхәббәте гаҗәеп зур эмоциональ көч һәм сәнгатьчә камиллек белән гәүдәләнә.

Моабит шигырьләре шагыйрьне әдәбиятның бөтен дөнья орбитасына алып чыкты. Бу шигырьләр, СССРдагы барлык милли телләргә тәрҗемә ителүдән тыш, инглиз, француз, испан, немец, гарәп, япон, венгр, румын, чех, корея һәм башка чит ил халыклары телләрендә дә кат-кат басылдылар.

Милли каһарманыбыз Муса Җәлил һәм җәлилчеләр узган данлы юл – халкыбызның горурлыгы ул. Тамчыда кояш чагылгандай, анда милли яшәешебезнең тарихы да калку гәүдәләнә. Шуңа күрә герой-шагыйрьнең үлемсез иҗаты, җәлилчеләрнең тиңдәшсез, героик көрәше безнең өчен бүген дә гаять зур әһәмияткә ия.



# Тәрбияле бала сәхифәсе

Бүген сәхифәбездә әдәплелек турында сүз алып барырбыз.Сез үзегезне әдәпле, тәрбияле бала дип уйлыйсызмы? Нинди була соң ул- әдәпле бала.? Без һәрвакыт ул кагыйдәләрне үтибезме?

Ул кагыйдәләрне кем уйлап чыгарды икән? Уйланырга урын бар!

«Әдәплелек» сүзен син ничек аңлыйсың? Әдәпле булу - башка кешеләргә карата игътибарлы булу, дөрес аралаша белү дигән сүз. Әдәпле кеше белән аралашу рәхәт, шуңа күрә андый кешене һәркем ярата, хөрмәт итә. Гадел, саф күңелле, намуслы, эчкерсез, сабыр булу - әдәплелек сыйфатлары.

Һәр кеше дусларыннан, күршеләреннән, танышларыннан, хәтта бөтенләй таныш булмаган кешеләрдән дә игътибар, ягымлы сүз һәм хөрмәт көтә. Беркемнең дә башкалардан начар, усал сүзләр ишетәсе килми. Әдәпле булу «Исәнмесез» сүзеннән, кешеләрнең бер -берсе белән елмаеп исәнләшүеннән башлана. Тәрбияле, әдәпле кешегә башкалар, гадәттә, яхшылык белән җавап бирәләр. Шундый кешенең генә ышанычлы дуслары, танышлары була.



Әдәплелек кагыйдәләре бик күп. Өйдә, мәктәптә, урамда, транспортта, кибеттә, подъездда, лифтта - кыскасы, һәркайда үзеңне әдәпле яки әдәпсез тотарга була. Әдәпле булу өчен, әдәплелек кагыйдәләрен белү генә җитми, аларны үтәү бик мөһим. Ләкин иң элек әдәпле булу теләге кирәк.

Әдәпле кеше һәрвакыт үзенең якыннарына, дусларына һәм бер дә таныш булмаган кешеләргә дә ярдәм итәргә әзер. Әдәплелек кагыйдәләрен үтәргә күнегергә кирәк. Мәсәлән: -транспортта өлкәннәргә, балалы хатын-кызларга урын бирергә; -аларга транспортка керергә һәм аннан чыгарга булышырга:

- транспортта кычкырып сөйләшмәскә; ачу килгәндә дә тупас сүзләр әйтмәскә;
- кешеләрнең хәленә керә белергә, башкаларны беркайчан да кыен хәлгә куймаска,
- ялганламаска, әйткән сүзеңдә торырга;
- башкалар сөйләгәндә игътибар белән тыңларга, бүлдермәскә һәм кирәк чакта гына сүзгә кушылырга;
- гайбәт сөйләмәскә, мактанмаска, үзеңне тыйнак тотарга һ.б.

Редакциянең адресы:420101, Казан шәһәре, Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576 Тираж – 50 экз.

Баш мөхәррир һәм дизайнер:
Габдуллаҗанова А.Ф.

Редколлегия әгъзалары:
Соколова София, Овезова Ләйлә, Сафина Камилла, Акмаева Элиза